СИШӘМБЕ
26 МАРТ
1940 ел
№ 70 (5870)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик һәм культура бүлекләре 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

РАДИО РАБОТНИКЛАРЫНА ВКП(б) ҮЗӘК КОМИТЕТЫ ҺӘМ СССР СОВНАРКОМЫ КОТЛАВЫ

ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм ССР Союзы Совнаркомы СССР да киң радио-хәбәрләшүенең XV еллыгы уңае бедән совет радио работникларын котлыйлар.

ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм ССР Союзы Совнаркомы XV ел эчендә совет радио-хәбәрләшүе өлкәсендә ирешелгән зур уңышларны күрсәтеп үтәләр.

ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм ССР Союзы Совнаркомы радио-хәбәрләшү работникларын дәүләт тарафыннан бирелгән барлык мөмкинлекләрдән файдаланып, хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләүдә һәм аларның культура дәрәҗәләрен һәр яклап күтәрүдә совет радио-хәбәрләшүен тагын да куәтлерәк средство итеп әверелдерергә чакыралар.

ВКП(б) ҮЗӘК КОМИТЕТЫ. ССР СОЮЗЫ СОВНАРКОМЫ.

ХЕЗМӘТ ҖИТЕШТЕРҮЧӘНЛЕГЕН КҮТӘРҮДӘ ӘҺӘМИЯТЛЕ ШАРТ

Ленин—Сталин партиясе тәрбияләп үстергән, бөек совет Ватанына чиксез бирелгән кешеләр, яңалыкны башлап йөрүче инициаторлар—производство һәм техника новаторлары хезмәт житештерүчәнлеген күтәрү өчен, җан башына туры килә торган продукциянең күләмен арттыру өчен безнең хуҗалык системасында, промышленность һәм транспорт предприятиеләрендә гаять зур резервлар барлыгын үз тәҗрибәләрендә күрсәтеп киләләр. Алар кыю рәвештә иҗад итәләр, предприятиеләрнең куәтен үзләштерүгә карата, производствоны һәм техниканы өзлексез яхшыртуга карата кыйммәтле һәм бик файдалы яңалыклар кертәләр.

Социалистик промышленностьның кайсы гына тармагын алып карасаң да үзенең рационализаторлары һәм уйлап табучылары бар. Алар безнең илебездә мактаулы урын тоталар. Партия һәм Совет хөкүмәте аларны тәрбияләп үстерү, талантлы, иҗад итүче кадрларның рационализаторлык такдимнәрен тормышка ашыру турында һәр вакыт кайгырталар. „Иптәш Сталин уйлап табуга һәм уйлап табучыларга зур игтибар бирергә кирәклекне хуҗалык наркоматларына күп тапкырлар күрсәтеп килде. Хуҗалыкчылар уйлап табучыларны һәр яклап кызыксындырырга һәм аларга булышлык итәргә, шулай ук аларның эше өчен кирәк булган барлык шартлар белән аларны тәэмин итәргә тиешләр“ (Л. М. Каганович).

Рационализаторлар һәм уйлап табучылар партия һәм Совет хөкүмәтенең бу кайгыртучанлыгына эш белән, иҗади активлыкның яңа күтәрелеше белән җавап бирәләр. Безнең илебез уйлап табулардан, производствога, техникага, машиналарга һәм станокларга яңалык кертүләрдән, средстволарны, көчләрне һәм чималны азрак тотып күбрәк санда продукция эшләп чыгарудан һәр ел саен күп миллионнарча сум экономия ясый. Меңнәрчә һәм күп меңнәрчә рационализаторлар һәм уйлап табучылар үзләренең кыйммәтле такдимнәрен кертеп, халык хуҗалыгының бу фондын арттыруга, социалистик экономиканы тагын да ныгытуга һәм үстерүгә, хезмәт житештерүчәнлеген өзлексез күтәрә баруга зур этәргеч бирәләр.

Без моның ачык мисальләрен республикабызның күп предприятиеләрендә күрә алабыз. М. Горький исемендәге завод стахановчылары, талантлы инженер-техник работниклары үткән елны йөзләрчә такдим кертеп, дәүләткә 203 мең сум экономия биргәннәр иде. Быел заводның уйлап табучылары рационализация исәбенә 375 мең сум экономия бирү йөкләмәсе алдылар. Бу әһәмиятле бурычны үтәү өчен алар большевистик инициатива һәм тырышлык белән көрәшәләр.

Орденлы Татарстанның данлыклы XX еллык бәйрәмен яңа уңышлар һәм производство казанышлары белән каршылау өчен социалистик ярышны башлап җибәргән мехчылар уйлап табу өлкәсендә дә актив эш алып баралар. Үткән елны мехкомбинатта 110 такдим тормышка үткәрелеп, 1 миллион сум экономия ясалган иде. Быел комбинатның уйлап табучылары рационализация исәбенә 1 миллион ярым сум экономия бирү йөкләмәсе алдылар.

2 нче мех фабрикасының чимал цехы начальнигы Маслов, 1 нче мех фабрикасы инженеры Биншток иптәшләрнең катлаулы производствода хезмәт житештерүчәнлеген күтәрү буенча керткән такдимнәре аеруча характерлы. Аларның такдимнәре үзләре генә дә комбинатка йөз меңнәрчә экономия бирәләр.

Алар аз түгел. Үзләренең бөтен эшләрендә һәм көрәшләрендә социалистик милеккә, хезмәткә аңлы карашның югары үрнәкләрен чагылдыручы стахановчылар һәм инициативалы, яңалыкка киң юл ачучы, аны үстерүгә булышучы инженер-техник работниклар, мастерлар, бригадирлар, производство командирлары арасыннан күп санда рационализаторлар һәм уйлап табучылар үсеп чыгалар. Бу иптәшләрнең бөтен эшләренә, һәр яңалыкны башлап йөрүләренә булышлык итәргә, аларның кыйммәтле такдимнәрен вакытында һәм тулысынча тормышка үткәрү өчен барлык шартларны тудырырга кирәк.

Ләкин кайбер предприятие җитәкчеләре рационализаторларга һәм уйлап табучыларга булышмыйлар, аларның файдалы такдимнәрен күрмиләр. 3 нче фанер заводында стахановчыларның такдимнәре еллар буенча нәтиҗәсез яталар. Стахановчы иптәш Силин үзенең бай тәҗрибәсе нигезендә токарь станогына әһәмиятле үзгәрешләр кертү турында такдим биргән иде. Аннан соң бер ел вакыт үтеп китте инде. Стахановчы үзенең такдимен тормышка үткәрү өчен завод җитәкчеләреннән шушы көнгә кадәр тиешле булышлыкны ала алмый.

Язу машиналары заводында да бу эш мактарлык түгел. Беспалов, Стрекалов, Ильин һәм башка иптәшләрнең гаять әһәмиятле такдимнәре озак вакытлардан бирле хәрәкәтсез яталар. Уйлап табучы иптәшләрнең инициативасын болай бюрократларча карау башка предприятиеләрдә дә очрый. Мондый киртәләргә чик куелырга тиеш. „Күп санлы уйлап табучылар, рационализаторлар һәм аларның ярдәмчеләре турында чын-чынлап кайгыртучан булу безнең өчен гаять күп яңа резервлар ачачак. Бу эшне, иптәш Сталин өйрәткәнчә, актив рәвештә, материаль һәм иҗтимагый чаралар белән дәртләндерергә кирәк һәм аны алга барырга кирәк“ (Молотов).

Иптәш Молотовның бу күрсәтмәсе хуҗалык наркоматлары җитәкчеләренә, производство командирларына һәм бик кагыла. Алдынгы предприятиеләр уйлап табучылык буенча җәмәгать смотрлары үткәрү практикасын киң кулланалар. Мондый смотрларны барлык предприятиеләрдә үткәрергә кирәк. Җәмәгать смотрлары бу өлкәдә булган кимчелекләрне ачуга, рационализаторларның һәм уйлап табучыларның активлыкларын арттыруга, производствоның иң әһәмиятле мәсьәләләре белән аларның эшләрен тыгызрак бәйләүгә ярдәм итәчәк. Рационализаторлар арасында массакүләм эш алып бару, аларның иҗтимагый эшләрен дә активрак рәвештә оештыру, уйлап табуны киң җәелдерергә кирәк.

Хуҗалыкчылар, партия һәм профсоюз оешмалары уйлап табу эшенә хезмәт житештерүчәнлеген күтәрү буенча өченче бишьеллыкның дүрт елда үтәү өчен иң әһәмиятле шартларның берсе итеп карарга, аңа большевистик җитәкчелек итәргә, ныклы булышлык күрсәтергә тиешләр.

ТАСС тан

СССР Совнаркомы Председателе иптәш Молотовның Берлингә, шулай ук Германия яки Көнбатыш Украина шәһәрләренә берсенә барырга уйлавы турында төрле ил һәм агентлыклары тарафыннан таратыла торган хәбәрләрнең һичбер нигезсез икәнлеген белдерергә ТАСС ның вәкаләте бар.

Украина ССР һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләрендә Верховный Советларга сайлаулар зур оешканлык белән үтте

Сталин Конституциясе байрагы астында

24 нче мартта УССР ның һәм БССР ның көнбатыш өлкәләре хезмәт ияләре үзләренең иң яхшы кешеләрен СССР, УССР һәм БССР Верховный Советларына сайладылар.

Панның изүеннән азат ителгән кардәш халыклар бу көнне үзләренең тавышларын коммунистларның һәм партиясезләрнең Сталинчыл блогы кандидатларына бирү өчен сайлау урыннары янына бардылар. Алар сайлауларга СССР ның Сталин Конституциясе байрагы астында, бөек Ленин—Сталин партиясенә, социалистик Ватаныбызга карата кайнар мәхәббәт белән рухланып бардылар.

Кешеләрчә тын тормыш өчен!

ТАРНОПОЛЬ. Моннан җиде ел элек, март төнләренең берсендә, Тарнопольдәге эшсез Шлекерның кыйгаең беткән йортына жандармнар кереп, аның 15 яшьлек кызын—комсомолка Минаны кулга алдылар.

Жандармнар талаган өйдә иртә беләнгә кадәр ут янды, аннан җылау һәм ыңгырашу тавышлары ишетелеп торды.

...1940 нчы елның 24 нче мартында карашы төндә эшче Шлекерның квартирасында лампа иртә беләнгә кадәр янып торды. Ул үзе, хатыны, кызлары йоклый алмадылар. Иртән 5 сәгатьтә алар инде 9 нчы сайлау участкысында иде.

Шлекерлар беренче булып тавыш бирделәр.

Сайлау урыннары янына яшь эшче хатын-кызлар, студентлар, карт аналар килде.

Көндез 12 сәгатьтә бу участокда сайлаучыларның яртысы чамасы тавыш биреп бетерде.

Үзләренең гражданлык бурычларын үтәгәннән соң, сайлаучылар озак вакытлар өйләренә кайтмыйча торалар. Урамнар халык белән тулган. Азат ителгән җирдә бәхетле башланган яңа тормыш турында украин халкы җырлары яңгырый.

Белосток текстильчеләре тавыш бирәләр

БЕЛОСТОК. Шәһәр иртә уянды. Таң алды сәгатьләренең тынлыгын радио бозды. Репродукторлардан совет җырлары тапшырылар. Шәһәрнең үзәгендә дә һәм читләрендә дә—һәр җирдә шатлыклы, күтәренке настроение сизелә. Бер-берсенә таныш булмаган кешеләр бөтен халык бәйрәме белән котлашалар.

Пролетарский сайлау округының 52 нче участкысы. Бу участокы урнашкан бина элек фабрикант Маркусның иде. Хәзер монда беренче текстиль комбинатының дирекциясе урнашкан. Сайлаучыларның үзләренең тавышларын коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатларына бирергә чакыра торган лозунглар язылган кызыл полотнолары җил җилфердәтә. Фабрика корпусларында иптәш Сталинның һәм аның көрәштәшләренең зур портретлары. Моннан бер ел элек бу корпусларда станоклар айлар буе эшсез тордылар. Ә 1940 нчы елның 23 нче мартында комбинатның стахановчылары квартал планын үтәделәр.

Участкы сайлаучылары туктаусыз агылып торалар. Аларның һәр кайсы шатланып сайлаулалар, сайлаучылар исемлекләрен тикшерә торган өстәл янына җибәрәләр. Алар арасында иң яхшы вәкилләренең: Көнбатыш Белоруссия хезмәт ияләренең азат итү операциясендә җитәкчелек иткән командарм Ковалевның, инженер Турлейскийның һәм беренче комбинатның стахановчысы эрләүчесе Петровскаяның исемнәре язылган сайлау бюллетеннәре алалар.

Сталин исме белән

ЛЬВОВ. Иртә. Ун меңнәрчә граждан дөньядагы иң демократик сайлауларда беренче булып сайларга ашыгалар. Йортлар лозунглар, транспарантлар һәм матур коверлар белән бизәлгән.

Ягелонски урамындагы 12 нче номерлы йорт ишек алдына кешеләр җыелган. Алар—Сталин Конституциясен өйрәнү түгәрәге катнашучылар. Алар сайлау участкысына барсы бергә барырга булганнар.

Жовкивский урамындагы 88 нче йортта 15 нче номерлы сайлау участкысы урнашкан. Участкы бинасында — предприятиеләрнең эшчеләре, тимер юлчылар, йорт хозяйкалары, 60—70 яшьлек картлар һәм карчыклар, яшьләр. Һәммәсенең дә йөзе ачык, бәхетле, барсы да бәйрәмчә киенгәннәр.

... Эшчеләр бистәсе Габриловка. Шевченко сайлау округының 23 нче номерлы сайлау участкысына иртән 6 сәгатьтә 200 дән артык кеше җыелды.

Агитпунктка карт эшче, трамвайчы Петр Васильевич Савко керә. Ул әле генә тавыш биреп чыккан һәм иптәшләренә үзе турында, тормышы турында сөйли.

Меңнәрчә кешеләрнең үзләренең иң яхшы вәкилләренә тавыш бирүче эшчеләрнең, крестьяннарның, интеллигентларның, азат ителгән халыкның телендә чиксез кадерле һәм якын Сталин исеме.

... Львов урамнарында шатлыклы музыка, дәртле җыр тавышлары төннең уртасына кадәр яңгырап торды. Һәр җирдә дә яз сизелә, һәр җирдә дә—бөтен халыкның зур бәйрәме.

24 март. (ТАСС).

Икенче „Алтын Йолдыз“ медале белән бүләкләнгән Советлар Союзы Герое комдив иптәш С. П. Денисов.

БАТЫР СУГЫШЧЫЛАРНЫ КАРШЫЛАУ

ЛЕНИНГРАД, 23 март. (ТАСС). Ун меңнәрчә хезмәт ияләре урамнарга чыктылар. Йортлар флаглар белән бизәлде. Кызыл полотноларга „Ленин шәһәрен саклаучы геройларга дан!“, „Җиңелмәслек Кызыл Армия сугышчыларына сәлам!“ дигән котлау сүзләре язылган.

Киров атауларындагы Елагин күпере янында халык тулы. Күз карашлары төньякка таба сузылган шоссегә юнәлгән. Менә еракта беренче автомашина күренә. Алда байрак янында чәчәкләргә төрелгән бөек Сталин портреты.

Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен „Кызыл Байрак“ ордены белән бүләкләнгән 169 нчы моторлаштырылган укчы полкның бөтен колоннасы күренә башлады. Данлыклы 169 нчы полк йөзләрчә батыр һәм кыю сугышчылар тәрбияләп үстерде. Аларның дүртесе—полковник Зашибалов, кече лейтенант Сабиров, өлкән лейтенант Пузанов, кызыл армеец Ксенофонтов Советлар Союзы Геройлары исме алдылар.

Машиналар туктый. Трибуна янында кыскача митинг башлана. Советлар Союзы Герое иптәш Пузанов речь сөйли. Ул болай ди:

— Безнең изге чикләребезгә кул сузарга батырчылык итүче һәрбер дошманны безнең данлыклы сугышчыларыбыз партиянең һәм хөкүмәтнең беренче чакыруы белән үк яңадан тар-мар итәргә хәзер торалар.

Иптәш Пузанов Кызыл Армиянең гүзәл командирларына һәм полководецларына, Советлар Союзы маршалы К. Е. Ворошиловка, иптәш Сталинга сәламәтлек теләде.

Мәйданда озак „ура“ тавышы яңгырап тора.

Ленинград хезмәт ияләре исеменнән сугышчыларны, командирларны һәм политработникларны ВКП(б) ның шәһәр комитеты секретаре иптәш Маханов һәм судоверф стахановчысы иптәш Зыганов котлыйлар.

Кызыл Армиябезнең героик батырлыклары тарихына яңа сәхифә язган данлыклы полкны ленинградлылар зур күтәренкелек белән каршы алдылар.

СОВЕТ РАДИО ТАПШЫРУЫНЫҢ 15 ЕЛЛЫГЫ

Союзлар Йортының Колонналы залында тантаналы утырыш

Үзләренең 15 еллыкларын билгеләп үтүче совет радио тапшыруы работниклары миллионнарча радио тыңлаучылар алдында соңгы ун көн буена отчет бирделәр. Иң яхшы артистлар, ансамбльләр һәм коллективлар микрофон алдында иҗад рапортлары белән чыктылар. Юбилей декадасының соңгы көнендә—23 нче мартта Союзлар Йортының Колонналы залында (Москва) тантаналы утырыш булды. Залга радионың карт работниклары, уйлап табучылар, галимнәр, артистлар, композиторлар, язучылар, радио-сөючеләр җыелдылар. Президиумда—СССР Совнаркомы председателенең урынбасары иптәш Вышинский, Советлар Союзы Герое иптәш Кренкель, СССР ның халык артисткасы иптәш Яблочкина, РСФСР ның халык артисты иптәш Гольденвейзер, академик иптәш Келлер, орденлы язучылар Маршак һәм Федин иптәшләр, башкала фабрикаларының һәм заводларының вәкилләре.

Бөтенсоюз радиокомитеты председателе иптәш Г. И. Стуков радио тапшыруының 15 еллыгы турында доклад ясады.

Соңгы 15 ел эчендә совет радиосы зур уңышларга иреште. Радио тапшыруга акча җибәрү елдан-ел үсә. 1935 нче елны бу эшкә 62 миллион сум җибәрелгән иде, ә быелгы план буенча 200 миллион сум җибәрү күздә тотыла. Радио буенча партия пропагандасы һәм агитация алып бару елдан-ел яхшыра.

СССР Совнаркомы председателенең урынбасары иптәш А. Я. Вышинский зур речь сөйләде. Ул болай диде:

— Миңа радио работникларын партия Үзәк Комитеты һәм СССР Халык Комиссарлары Советы исеменнән котларга рөхсәт итегез. Киң күләмдә оештырылган совет радио тапшыруының 15 елы җитәрлек күләмдә зур уңышлар белән данлыклы. Радио—тормышыбызның көндәлек юлдашы булып әверелде. Радио илебезнең һәрбер почмагына үтеп керде дип, көндәлек тормышыбызның аерылгысыз өлеше булып әверелде дип ышаныч белән әйтергә мөмкин. Әле күптән түгел генә, 1921 нче елны, Владимир Ильич, радионың үсеше белән армый-талмый һәм һәр вакыт кызыксынып, ул вакытта әле туып кына килә торган эшнең җитәкчеләре алдына шушындый сорауларны куйган иде: үзәк станция көненә ничә сүз тапшыра, ничә чакрымга, Москва сөйли торганнарны урамда, яки залда тыңларга мөмкинлек бирә торган аппаратлар бармы һәм ничәү. Менә элек булганнарны хәзер без күрә торганнар белән чагыштырып карагыз!

— Әле яшь учреждение булган радиокомитетның эшендә һич шиксез уңышлар бар һәм иң әһәмиятлесе—ул, аның туплый алган кадрлары. Без дикторлар белән дә, җырчылар белән дә, хор һәм оркестр белән дә һәм аларның гүзәл җитәкчеләре белән дә горурлана алабыз. Ләкин әле күп бурычларның хәл ителмәгәнлеген онытырга ярамый. Радио—пропаганданың һәм агитациянең әһәмиятле коралы, кешеләрне коммунистик тәрбияләү коралы, иң киң магнәсе белән алганда мәгариф коралы. Бу магнәдә алганда радио киногa нык якынлаша. Болар барсы да радио работникларына зур җаваплылык йөклиләр. Алар алдында һәм радиокомитет алдында җидди бурычлар тора һәм аларның иң әһәмиятлесе—бөтен дөнья радио-техникасының барлык соңгы казанышларыннан файдалану өчен көрәшү, радионы социализм иленнән башка,—безнең Ленин—Сталин партиясенең җиңүчән байрагы югары һәм горур җилферди торган илдән башка бер генә илдә була алмый торган куәтле көч итеп әверелдерү.

Утырышта Советлар Союзы Герое иптәш Кренкель, орденлы язучы иптәш Федин, орденлы композитор иптәш Хачатурян, академик иптәш Келлер һәм Сталин исемендәге автозавод вәкиле иптәш Захаров котлау речьләре сөйләделәр. Аннары җырчыларның, дикторларның, редакторларның, әдәби работникларның, режиссерларның, эшчеләрнең, монтажчыларның зур группасын юбилей значоклары, грамоталар һәм акча белән бүләкләү турында Бөтенсоюз радиокомитетының приказы игълан ителде.

Утырышта зур күтәренкелек белән Сталин һәм Молотов иптәшләргә котлаулар кабул ителде.

Тантаналы утырыштан соң зур юбилей концерты булды.

(ТАСС).

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

ПАРТИЯ ПРОПАГАНДАСЫНА ЖИТӘКЧЕЛЕКНЕ ЯХШЫРТЫРГА

Житәкче урыннарда эшләүче коммунистлар марксизм-ленинизм нигезләрен өйрәнүдә үрнәкле булырга тиешләр иде. Ләкин Норлат районындагы кайбер житәкче работниклар моның киресен күрсәтәләр. Мәсәлән, РАЙФО мөдире Вәлиев, РОНО мөдире Җәләлиев, РАЙЗО мөдире Гыйрфанов һәм МТС директоры Заһидуллин иптәшләр бер елдан артык инде „Кыскача курс" ның I—II нче бүлекләрен „укыйлар".

Кайбер башлангыч партоешмаларның секретарьлары ВКП(б) тарихын үзләре ныклап өйрәнмиләр һәм коммунистларга да бу эштә ярдәм итмиләр. „Активист" (партоешма секретаре иптәш Фатыйхов) һәм „Кечле юрек" (партоешма секретаре иптәш Шакиров) колхозларындагы башлангыч партоешмалар партия пропагандасы мәсьәләләре белән бик аз шөгыльләнә. Коммунистларның үз өсләрендә ничек эшләүләрен бер кем дә белми һәм тикшерми. Шуңлыктан бу оешмаларның коммунистлары үз белемнәрен күтәрү өстендә бөтенләй диярлек эшләмиләр.

„Игенче" колхозындагы партоешма янында партия тарихын өйрәнү буенча түгәрәк оештырылган иде. Ләкин бик күптәннән инде бу түгәрәктә занятиеләр булмый. Башлангыч оешма да, шулай ук райком пропагандистлары да бу түгәрәкнең эшен юлга салу чараларын күрмиләр.

Район парткабинеты тарафыннан уздырыла торган лекцияләр һәм консультацияләрне оештыру эшенә дә соңгы вакытта житәрлек игътибар итми башладылар. Бу турыда оешмаларга һәм гомумән партия тарихын өйрәнүчеләргә алдан белдерү ясалмый, бәлки лекция яки консультация булачак көнне генә хәбәр ителә. Шуңлыктан күп кенә иптәшләр консультациягә ныклап хәзерләнми киләләр.

ВКП(б) райкомының агитация һәм пропаганда бүлеге мөдире иптәш Кавиев кабинетта утырып партия тарихын өйрәнүчеләр турында статистик саннар алу белән генә шөгыльләнә. Башлангыч оешмаларда сирәк була. Шуңлыктан районда агитация һәм пропаганда эшенең тиешле хәлдә булмавы ...

Бу фактлар Норлат районында партия пропагандасын оештыру һәм аңа житәкчелек итүдә әлегә кадәр житди кимчелекләр яшәгәнлекне күрсәтәләр. ВКП(б) ның район комитеты бу кимчелекләрне бетерү өчен кискен чаралар күрергә тиеш.

Х. Хәлилев.

АГИТАЦИЯ ЭШЕН ОНЫТКАННАР

Саба районындагы Сатыш авылы районда иң зур авылларның берсе. Бу авылда тулы булмаган урта мәктәп, сельпо, тегү артеле бар. Бу авылда интеллигенция кадрлары шактый күп. Бер урта мәктәптә генә дә 12 ләп укытучы бар. Монда партия оешмасы һәм комсомол оешмасы да бар. Бер сүз белән әйткәндә, культура-масса һәм тәрбия эшләрен җәелдерү өчен көчләр житәрлек һәм мөмкинлекләр зур.

Сайлаулар вактында бу авылның агитаторлары начар эшләмәделәр. Укытучыларның барсы да диярлек, агитаторлар иде. Укытучы иптәш Гайнеттинев агитколлективның житәкчесе булып эшләде. Агитация эшен оештыруда сәләтле булуын да күрсәткән иде. Ләкин сайлаулар үткәннән соң ул агитаторлар белән эшләүне бөтенләй туктатты. Сайлаулардан соң хәзергә кадәр агитколлективның бер генә семинары да булганы юк. Укытучы-агитаторлар да инициатива күрсәтмиләр. Алар хәзер мәктәп тирәсендә генә әйләнәләр, колхозчылар арасына чыгып бер нинди дә аңлату эшләре алып бармыйлар.

Гомумән алганда Сатыш авылында агитация эшен оныттылар. Партия һәм комсомол оешмаларының житәкчеләре агитация эшен җанландыру чарасын күрмиләр. Колхозчылар массасын 1940 нчы елда югары иген уңышы алу өчен көрәшкә тупламыйлар.

Агитация эшенең шулай онытылуы нәтиҗәсе буларак, соңгы вакытта колхозда хезмәт дисциплинасы йомшарды, колхозчыларның производство активлыгы шактый кимеде. Язгы чәчүгә хәзерлек, агрономия чараларын үткәрү, юл төзелеше эше, урман хәзерләү һәм башка эшләр буенча колхоз хурлыклы рәвештә артка кала башлады.

Агитация-масса эшенең торышы Олы Шынар, Мәнгәр һәм башка кайбер авылларда да шундый ук хәлдә. Андагы агитколлектив житәкчеләре һәм агитаторлар да үз эшләрен оныттылар. ВКП(б) ның Саба райкомы моннан тиешле нәтиҗә ясарга тиеш.

Исламов.

Главпищепром карамагындагы тара фабрикасы эшчеләре „Китап өстендә ничек эшләргә" дигән темага лекция тыңлыйлар. Лекцияне иптәш А. Ярмөхәметова укый. М. Солтанов фотосы.

Партиянең район активы җыелышлары

ТЕЛӘЧЕ РАЙОНЫНДА

Партиянең Теләче район активы җыелышы булып үтте. Җыелышта ВКП(б) ның Татарстан оешмасының XXI нче өлкә конференциясе йомгаклары турында райком секретаре иптәш Бусарев доклад ясады. Фикер алышуларда 18 коммунист катнашты. Алар политик агитация эшен җәелдерү буенча кайбер урыннарда агитколлективларның йомшак эшләвен, язгы чәчүгә хәзерлек эшенә оператив житәкчелекнең житәрлек булмавын күрсәтеп үттеләр.

Актив партиянең өлкә конференциясе карарларын тормышка ашыру буенча практик чаралар билгеләп, карар кабул итте.

Заманов.

ЯҢА ЧИШМӘ РАЙОНЫНДА

Яңа Чишмә районында партия һәм комсомол активы җыелышы үткәрелде. Партиянең XXI нче өлкә конференциясе йомгаклары турында ВКП(б) райкомы секретаре иптәш Алешковның доклады зур игтибар белән тыңланды. Фикер алышуларда 17 кеше катнашты.

Актив җыелышы партиянең өлкә конференциясе карарларын яхшы дип тапты һәм аларны үтәү өчен конкрет чаралар билгеләде.

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНДА

Октябрь районында партия активы җыелышы булды. Актив партиянең XXI нче өлкә конференциясе йомгаклары турындагы мәсьәләне тикшерде. Җыелышта 80 кеше катнашты.

Бу мәсьәлә буенча фикер алышуларда 14 кеше чыгып сөйләде. Алар район җир бүлегенең һәм МТС ның йомшак эшләүләрен күрсәтеп үттеләр. Иптәш Волков үзенең чыгышында болай диде:

— Партия оешмасының VI нчы район конференциясеннән соң бер айга якын вакыт узып китте. Ләкин район җир бүлеге һәм МТС работниклары язгы чәчүгә хәзерлектә артта калуны бетерү чараларын күргәннәре юк әле. Чәчү орлыкларының 50 проценты кондициягә житкерелмәгән. 72 колхозның 56 сында гына звенолар оештырылган. Тракторларга ремонт ясау эше өзеклектә.

Җыелыш районның коммунистларын язгы чәчүгә хәзерлектәге житешсезлекләрне тиз арада бетерергә, колхозчылар арасында агитация-масса эшен киң җәелдерергә чакырып карар кабул итте.

Партбюроның яңа составы эштә

Максим Горький исемендәге завод партбюросының яңа составы (секретаре иптәш Ксенжук) отчет-сайлау җыелышы карарларын тормышка ашыру буенча планлы эш алып бара.

Оешманың эш планын төзегәндә, отчет-сайлау җыелышында коммунистлар тарафыннан күрсәтелгән тәкдимнәр күздә тотылды. Оборона-физкультура эшен һәм дингә каршы пропаганданы яхшырту чаралары билгеләнде. Балаларны коммунистик тәрбияләү мәсьәләсе буенча эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомуми җыелышы үткәрелде. Партбюро агитколлектив житәкчеләре белән киңәшмә үткәрде.

Отчет-сайлау җыелышында коммунистлар хуҗалык эшләренә партбюро тарафыннан житәкчелекнең йомшак булуын күрсәткәннәр иде. Партбюро моны искә алып, бу өлкәдә күп кенә конкрет чаралар билгеләде. Бу мәсьәлә эшчеләр белән тикшерелде. Эшчеләр ул чараларны яхшы дип таптылар һәм эшне күрсәтелгән срокларда график буенча үтәргә йөкләмә алдылар. Күп кенә участкылар һәм бригадалар заданиеләрне арттырып үти башладылар. Коммунист мастер иптәш П. Гущин участкысы, Сергеев һәм Хәйруллин иптәшләрнең бригадалары айлык заданиене срогыннан элек үтәделәр.

(ТатТАСС).

Беренче уңышлар

Кукмара районы, Мәчкәрә авылы урта мәктәбе янындагы комсомол оешмасы (секретаре иптәш Кәлимуллин) үзенең эшен яхшы итеп куйды. Мәктәп комсомолецлары һәм союздан тыш яшьләр арасында политик-тәрбия эше киң җәелдерелде. Оешма алдынгы яшьләрне комсомолга тарту эше белән нык шөгыльләнә. Уку башланганнан бирле ВЛКСМ сафларына 29 кеше кабул ителде.

Оешмада эш план буенча алып барыла. Комсомол җыелышлары билгеләнгән вакытта, хәзерлек белән үткәреләләр. Җыелышларда дингә каршы пропаганда темаларына 8 доклад куелды. 18 комсомолец „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н үзлегеннән өйрәнә. Алар партия тарихын өйрәнүчеләр өчен оештырыла торган консультациягә регуляр рәвештә йөриләр. Мәктәптә ВЛКСМ ның программасын һәм уставын өйрәнү оештырылды. Комсомолецлар һәм союздан тыш яшьләр комсомол уставын зур кызыксыну белән өйрәнәләр.

ВЛКСМ членнарының барсына да порученияләр бирелгән. Иптәш Захаров комсомол оешмасының өченче секретаре һәм стена газетасының редакторы. 11 комсомолец колхозда агитатор булып эшли. 13 комсомолец ирекле җәмагать оешмалары түгәрәкләренә житәкчелек итә. Иптәш Заһидуллин Осоавиахим оешмасының председателе булып эшли. Иптәш Зәйнуллина учком эшен алып бара.

Порученияләрнең үтәлеше системалы рәвештә тикшерелә. Бу турыда комсомол җыелышларында аерым комсомолецларның информацияләре тыңлана.

ВЛКСМ оешмасы уку-укыту эшенә җидди игтибар итә. ВЛКСМ Үзәк Комитетының X нчы пленумы материалларын өйрәнү буенча үткәрелгән җыелышта уку елының өченче чирегең яхшы һәм отлично билгеләренә генә тәмамларга дигән карар кабул ителгән иде. Бу карар уку эшен яхшыртуга зур ярдәм итте.

Комсомолецлардан Шакиров, Закиров, Захаров, Хәсәнев, Зәйнуллина иптәшләр отличнога укыйлар. Усманов, Сабирҗанов, Шәйхеттинов, Заһидуллин иптәшләрнең уку елының икенче чирегендә икешәр-өчәр начар билгеләре бар иде. Өченче чиректә бу иптәшләр үзләренең укудан артта баруларын бетерделәр.

Комсомол оешмасы пионерлар оешмасы эше белән нык шөгыльләнә. Уку елы башланганда мәктәптә 120 пионер булса, хәзер аларның саны 248 гә житте. Пионер отрядларына 8 комсомолец житәкчелек итә. Пионер сборлары үз вактында үткәреләләр. Сборларда тарихи һәм фәнни темаларга докладлар куела.

Мәктәптә массовый оборона эшләре җанлы бара. Комсомол оешмасы бу эшкә нык игтибар бирә. Оешмада учетта торучы комсомолецларның барсы да винтовканы, гранатаны һәм пулеметны зур кызыксыну белән өйрәнәләр.

Болар әле башлангыч уңышлар. Без мәктәптә комсомол эшен ВЛКСМ Үзәк Комитетының X нчы пленумы таләпләре югарылыгына куюга ирешергә тиешбез.

Г. Сибгатуллин.

ВКП(б) тарихын өйрәнүчеләргә ярдәмгә

Профсоюз турында партиядә дискуссия

Ленин—Сталин партиясе житәкчелегендә эшчеләр һәм крестьяннар гражданнар сугышында җиңеп чыктылар. Гражданнар сугышында җиңеп чыгу—халыкара интервентларны тар-мар итү җиңел булмады.

Дүрт ел буена сузылган империалистик сугыш, өч елга сузылган гражданнар сугышы һәм күп кенә губерналарда булган каты ачлык илнең электә дә артта булган хуҗалыгын тагын да бөлгенлеккә китерде. Промышленность, транспорт һәм авыл хуҗалыгы җимереклеккә төште.

Сугышка кадәр вакыт (1913 нче ел) белән чагыштырганда 1920 нче елда цензовый промышленностьның (16 дан артык эшчесе булган предприятиеләр) эшләп житештерүе 18 процентка, металл промышленностенда эшләп чыгару (чуен кою) 2,4 процентка кадәр кыскарды. Гомумән промышленностьның продукциясе 7 тапкырга кимеде.

Патша Россиясендәге авыл хуҗалыгы бик түбән иде. Шуның өстенә, 1920 нче елда 1913 нче елгыга караганда авыл хуҗалыгы продукциясе 50 процентка якын түбәнәйде. Мәсәлән, 1913 нче елда 4.774 миллион пот ашлык житештерелгән булса, 1920 нче елда 2.944 миллион пот ашлык житештерелә. Һәм бу авылның үз кирәгенә дә житми иде. Шуның өстенә шәһәрдә эшләп житештерелгән әйберләр белән авылны тәэмин итү дә 1920 нче елда сугышка кадәргегә караганда 12 процентка кадәр түбәнәйде.

Бу хәлләр авыл белән шәһәр арасындагы экономик элемтә нигезләрен гаят дәрәҗәдә какшатты.

Советлар иле гражданнар сугышында җиңеп чыгу белән тыныч хуҗалык төзелеше рельсләренә күчкәч, крестьяннар хәрби коммунизм политикасына ризасызлык күрсәтә башладылар. „Ленин хәрби коммунизмның бөтен системасы крестьяннарнең интереслары белән бәрелешкә килүен күрсәтте". (ВКП(б) тарихы, бит 282).

Крестьян массалары арасындагы ризасызлык стихиясе эшчеләр сыйнфына да йогынты ясамыйча калмады. Революциянең һәм гражданнар сугышының авырлыкларын эшчеләр сыйнфы үзенең җилкәсендә алып барды—геройларча көрәштә күп корбаннар бирде. Ләкин промышленностьның җимерек хәлдә булуы нәтиҗәсендә эшчеләр сыйнфының материаль хәле бик начарланды. Эшчеләр сыйнфының бер өлеше авылларга китте. Эшче булудан туктап сыйнфи йөзен югалта башлады. Эшчеләр „зажигалка" һәм башка шуның кебек нәрсәләр эшләү белән шөгыльләнә башладылар. Болар барсы да вак буржуаз стихиясенең эшчеләр сыйнфына йогынты ясавы нәтиҗәләре булды.

Сыйнфи дошман хуҗалыкның авыр хәленнән файдаланырга маташты. 1920 нче елның көзендә һәм 1921 нче елның кышында Себердә, Украинада, Тамбов губернасында кулакларның ак гвардеецлар һәм эсерлар тарафыннан оештырылган мятежлары килеп чыкты. Контрреволюцион партияләр советка каршы көрәштә яңа тактик алымнарга күчтеләр. Аларның мондый тактик алымнары Кронштадттагы контрреволюцион мятеж вактында бигрәк тә ачык гәүдәләнде. Мятеж күтәрүчеләр „...Советчыл төскә буяна башлады һәм инде җимерелгән иске лозунгны: „Бетсен Советлар" дигән лозунгны түгел, бәлки яңа лозунгны: „Советлар өчен, ләкин коммунистлардан башка булган Советлар өчен" дигән лозунгларны алга сөрә башлады". (ВКП(б) тарихы, бит 283). Аларның советка каршы контрреволюцион көрәшләрендә троцкийчылар-бухаринчылар турыдан-туры ярдәм иттеләр.

***

Партия алдында хуҗалык һәм транспортның җимереклек шартларында сугыштан тынычлыкка күчүнең авыр бурычлары—яңа экономик политикага күчү бурычлары тора иде. Ленин бу чорны „Күчү чорында күчү чоры" дип атады.

„Сугышны бетергәч һәм тыныч хуҗалык төзелешенә күчкәч, хәрби коммунизмның сугыш һәм блокада шартларында килеп чыккан каты режимын саклау өчен инде нигезләр юк икәнлеге партиянең Үзәк Комитетына, аның Ленинчел күпчелегенә ачык иде". (ВКП(б) тарихы, 284 бит).

Партиянең Ленинчел—Сталинчыл Үзәк Комитеты бу кыенлыклардан чыгу өчен үз алдында төп бурыч итеп партиянең массаларга житәкчелек итү методын, профессионал союзларга берләшкән эшчеләр сыйнфының үзара мөнәсәбәтләрен, эшчеләр сыйнфы һәм советларның үзара мөнәсәбәтләрен яңа баштан үзгәртеп кору һәм сугыштан хуҗалык фронтына күчүнең яңа шартларында пролетариатның һәм крестьяннарнең үзара мөнәсәбәтләре турындагы мәсьәләләрне яңадан үзгәртеп кору бурычларын куйды.

Шушындый җаваплы, кискен, тарихи борылыш моментында, кыенлыклардан файдаланып партиянең һәм халыкның явыз дошманнары — троцкийчылар, бухаринчылар һәм башка шундыйлар профсоюзларның рольләре турында Үзәк Комитетның Ленинчел юлына каршы оппозицион группалар: троцкийчылар, „эшче оппозиция", „сул коммунистлар", „демократик централистлар" һәм башка шундыйлар атакага чыктылар. Профсоюзларның рольләре турындагы дискуссияне башлап җибәрүче Троцкий булды. „Троцкий артыннан партиягә каршы булган группалар да: „эшче оппозиция" (Шляпников, Медведев, Коллантай һәм башкалар), „демократик централистлар" (Сапронов, Дробнис, Богуславский, Осинский, В. Смирнов һәм башкалар), „сул коммунистлар" (Бухарин, Преображенский) чыктылар". (ВКП(б) тарихы, 286 бит).

Троцкийчылар платформасы, асылда, хәрби коммунизмнан яңа экономик политикага күчүгә каршы, социализмның җиңүен тәэмин итү өчен куелган чараларны тормышка ашыруга каршы көрәштән, хуҗалык политикасында да һәм массалар белән житәкчелек итүдә дә хәрби коммунизм методларын саклап калудан гыйбарәт иде.

Ленинның, массаларга житәкчелек итүдә яңа методларга күчәргә, коры командованиедән баш тартырга һәм профсоюзларны „коммунизм мәктәбе" итәргә дигән таләбенә каршы Троцкий үзенең канатлы лозунглары белән: „гайкаларны бору", „профсоюзларны селеккәләү", „профсоюзларны дәүләтләштерү" дип, массаларга житәкчелеккә көчләү методын көчәйтергә маташты.

1920 нче елның декабрендә Троцкий, үз платформасының төп положениеләрен биргән „профессионал союзларның рольләре һәм бурычлар турында" дигән брошюрасын яза. Ул монда марксизм-ленинизмга капма-каршы итеп, политиканы экономикага каршы куйды. Ленин аны фаш итеп:

„Политика, ул—экономиканың тупланган гәүдәләнеше... Политика экономикадан алда булмый кала алмый. Башкача фикер йөртү—марксизм элифбасын онту дигән сүз" диде. (Ленин, том XXIV—бит 126).

Троцкий платформасы: беренчедән, профсоюзларның бурычларын һәм рольләрен, аларның пролетариат диктатурасы чорында тоткан урыннарын бозудан; икенчедән, пролетариат һәм крестьяннарнең үзара мөнәсәбәтләрен капма-каршы куюдан, хәрби коммунизм политикасын дәвам иттерү һәм тирәнәйтүгә омтылудан; өченчедән, эшчеләр сыйнфы һәм аның авангарды—партиянең үзара мөнәсәбәтләренең Ленинчел куелышын бозудан; эшчеләр сыйнфының һәм Совет дәүләтенең үзара мөнәсәбәтләрен бозып күрсәтүдән гыйбарәт иде.

Ленин профсоюзларның рольләрен аңлатып „... профсоюзлар—идарә итүче, хөкүмәт башында торучы өстен сыйныфның, диктатураны тормышка ашыручы сыйныфның, дәүләт мәҗбүриятен тормышка ашыручы сыйныфның оешмасы. Ләкин ул дәүләт оешмасы түгел, ул мәҗбүр итү оешмасы түгел, ул тәрбия оешмасы, эшкә тарту, өйрәтү оешмасы, ул—мәктәп, идарә мәктәбе, хуҗалык итү мәктәбе, коммунизм мәктәбе" диде. (Ленин, XXVI том, бит 64).

Шуның белән бергә профессионал союзлар партияне эшчеләр сыйнфына, эшчеләр сыйнфы аркылы барлык хезмәт ияләре массаларына тоташтыру ролен үти.

Партиянең профсоюзлар турындагы бу күрсәтмәләренә каршы, троцкийчылар белән бер үк вакытта „эшче оппозиция" да күтәрелеп чыкты.

„Эшче оппозиция" дәүләт һәм хуҗалык органнарын профессионал союзларга буйсындыруны, хуҗалык белән идарә итүне профессионал союзларга тапшыруны таләп итте. Партияне һәм советларны хуҗалык белән житәкчелек итүдән читләштереп, „эшләп житештерүчеләр съездын" алга сөрде, „дәүләтне профсоюзлаштыруны" куйды. Шуның белән бергә партиянең һәм аның Үзәк Комитетының профсоюзларга житәкчелек итәргә тиешлеген инкар итте.

„Эшче оппозиция" партиянең һәм Совет дәүләтенең пролетар характерын, эшчеләр белән крестьяннар арасындагы союзның һәм безнең илдә социалистик төзелешнең җиңүе мөмкинлеген инкар итте. Партиянең авангардлык ролен, эшчеләр сыйнфының көрәшендә барлык оешмаларга житәкчелек ролен инкар итте. Профсоюзларны эшчеләрнең иң югары оешмасы дип санады. Профсоюзларны партиядән һәм аның Үзәк Комитеты житәкчелегеннән бәйсез итеп куярга омтылды. Дәүләт аппаратының пролетариат диктатурасының коралы булучылыгын инкар итте. „Дәүләтне союзлаштыруны" куеп, дәүләт властеның аппаратын профсоюзлар белән алмаштырырга теләде. Партия „эшче оппозиция" не, анархо-синдикализмда гаепләде.

„Эшче оппозиция"дә анархо-синдикалистлык: беренчедән партиянең эшчеләр сыйнфының авангарды булучылыгын инкар итүдән; икенчедән, дәүләт властеның органнарын инкар итүдән; партияне һәм дәүләт органнарын „партиясезлекнең стихиясе" белән алмаштырудан; өченчедән, пролетариат дәүләтендә демократик централизмның принципларына каршы мөнәсәбәттә булудан гыйбарәт иде. Билгеле анархизм һәм анархо-синдикализм партияне һәм аның кирәклеген инкар итә, пролетариатның иң югары сыйнфи оешмасы партия түгел, профсоюзлар дип карый.

Мондый анархо-синдикалистик карашка каршы Ленин иң кискен көрәш кирәклеген куйды һәм „эшче оппозицияне" фаш итеп: „Беренчедән, „житештерүче" дигән төшенчә пролетарийны ярым пролетарий белән һәм вак товар житештерүче белән берләштерә һәм шулай итеп, сыйнфи көрәш дигән төп төшенчәдән һәм сыйныфларны төгәл аера белергә дигән төп таләптән чигенә.

Икенчедән, партиясезләр массасына исәп тоту яки аның белән шаяру да—шулай ук марксизмнан тамырда ук чигенү" диде. (Ленин, том XXVI, бит 262).

Бухаринның „буфер" платформасы, нигездә троцкистик платформаны алганы хәлдә барлык өч платформадан да кисәкләп, эклетик төстә, асылда бер-берсенә бөтенләй капма-каршы булган кисәкләрне бергә бәйләргә тели. Бухарин Троцкийдан „профсоюзларны тизрәк дәүләтләштерү" идеясен нигез итеп алып, Лениннан эшчеләр демократиясе турындагы положение һәм „эшче оппозиция" дән, профсоюзлар тарафыннан куела торган „мәҗбүри кандидатуралар" турындагы положениене ала. Болар бер-берсенә капма-каршы булган положениеләр, берсенең икенчесенә кушылуы мөмкин булмаган эклектикадан гыйбарәт иде.

Ленин, Бухаринның „Буфер" платформасына карата: „Әгәр промышленность идарәсен профсоюзлар, ягни $^{9}/_{10}$ өлеш партиясез эшчеләр („мәҗбүри кандидатлар") билгеләсәләр—ул вакытта партия нәрсәгә? Бухарин әйткән нәрсә, логик, теоретик яктан да, практик яктан да партиянең аерылуы дигән сүз, дөресрәге: синдикалистларның партиядән аерылулары дигән сүз" диде. (Ленин, том XXVI, бит 92).

„Ленин, Бухаринның үз-үзен тотуын „идея ягыннан таркалуның иң югары ноктасы" дип атады. Бухаринчылар Ленингә каршы тиз арада троцкийчылар белән ачыктан-ачык берләштеләр" (ВКП (б) тарихы, 287 бит).

„Демократик централизм" группасы да шул ук троцкийчы, бухаринчылар шикелле үк, советларда һәм профсоюзларда партиянең житәкчелек ролен өзәргә тырыштылар.

Алар, фракцияләргә, группировкаларга тулы иреклелек таләп иттеләр. Буржуазия өчен политик иреклелек яулап алырга теләделәр. Бу платформа эсер-меньшевистик платформа иде.

Югарыда әйтелгән группалар Ленингә, Ленин—Сталин партиясенә каршы, профсоюзлар турындагы дискуссия дигән булып марксизм-ленинизмда төп мәсьәлә булган пролетариат диктатурасына, эшче һәм крестьяннар союзына, профсоюзларның рольләренә, пролетариатның партиясенә, ниһаять, бер илдә социализм төзүгә каршы чыктылар.

Большевиклар партиясе Ленин—Сталин житәкчелегендә партиянең X нчы съездында, күчү чоры кыенлыклары вактында килеп чыккан вак буржуаз группаларны, аларның идеяләрен фаш итте һәм тар-мар итте. Ленинизм җиңде.

Л. Гайфуллин.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮ АЛДЫННАН

ЮРТЫШ МТС ы КҮТӘРЕЛЕШТӘ

Дөбъяз районының Юртыш МТС ы 1939 елда республикада иң артта баручы МТС лар рәтендә иде. Ул үзенең эш планының бары 35 процент кына үтәде.

Артта калуның төп сәбәбе, беренчедән да элек, машиналардан файдалануга, кадрларны дөрес сайлап алуга, урнаштыруга һәм аларны тәрбияләүгә әһәмият бирмәүдә, хезмәт дисциплинасының начар булуында иде.

ВКП(б) ның Дөбъяз райкомы МТС ны бу хәлдән чыгару өчен күп кенә чаралар үткәрде. МТС ның элекке житәкчеләре яңалар белән алмаштырылды. Хәзер МТС директоры булып Актаныш МТС ының элекке директоры алтын медале иптәш Гәрәев эшли. Политик эшләр буенча директор урынбасары итеп райком МТС ка иптәш Вәлиуллинны жибәрде.

Яңа житәкчеләр эшне МТС ның артта калу сәбәпләрен җентекләп өйрәнүдән башладылар. Төп игтибарны кадрлар белән эшләүгә, хуҗасызлыкны, иясезлекне бетерүгә юнәлделәр.

МТС тракторларга ремонт ясау планы алдынгыларның берсе булып төгәлләде. Эшчеләр арасында социалистик ярыш һәм стахановчылык хәрәкәте шактый көчәйде, хезмәт дисциплинасы сизелерлек яхшырды.

Гәрәев һәм Вәлиуллин иптәшләр кадрлар белән аерым-аерым беседалар алып бардылар. Менә иптәш Гәрәев эшендәге характерлы моментларның берсе: тракторчы Сания иптәш Садыйкова үткән елларда МТС тагы эшен ташлап киткән иде. Иптәш Гәрәев Садыйкова белән һәм аның семьясе белән берничә тапкыр беседа үткәрә. Шуннан соң иптәш Садыйкова МТС ка кире кайта, эшли башлый. Хәзер ул үзен иң алдынгы стахановчы итеп танытты. Хезмәт ияләреннән район советы депутаты итеп сайланды. Иптәш Садыйкова ремонт ясау планын 24 нче декабрьдә ук үтәвенә карамастан, МТС мастерскоеннан киткәне юк, иптәшләренә булышлык күрсәтә.

Стахановчылар сафы көннән-көн үсә. МТС ның партия оешмасы (секретарь Вәлиуллин) эшчеләр арасында масса-аңлату эшләре алып баруга зур игтибар бирә. 1939 нчы елның сентябреннән бирле генә 20 алдынгы иптәшләрнең 16 кеше партия сафларына кабул ителде. Шулар арасында тракторчы Сания Садыйкова, Ярулин һәм Закиров иптәшләр бар.

МТС ның колхозларга җитәкчелеге дә яхшыра бара.

МТС коллективы быел республикада мактаулы урынны алу өчен көрәшә. Ләкин бу әле беренче генә адымнар. МТС ны алдынгы иту өчен әле күп эшлисе бар.

А. Әхмәдуллин.

Чистай—Яңа Чишмә районнары ярышы

ЧИСТАЙ. (Телефон буенча). 1940 нчы елда югары иген уңышы алуга ирешү өчен төзелгән социалистик ярыш договорының үтәлешен тикшерү буенча Чистай районы делегациясе Яңа Чишмә районында булды. Делегация „Яңа Тормыш“, Карл Маркс исемендәге һәм башка күп кенә колхозларда чәчүгә хәзерлекнең барышын тикшерде. Карл Маркс исемендәге колхоз чәчүгә хәзерлекне районда беренче булып төгәлләгән. Колхозның барлык бригадаларында социалистик ярыш договорлары төзелгән, алар 1940 нчы елда бөртекле культураларның һәр гектарыннан 16 шар центнер уңыш алырга ирешү өчен көрәшәләр. Колхозда чәчү орлыгы планлы артыгы белән тупланган һәм яхшы сыйфатлы итеп чистартып куелган. Орлыкларның сакланышы яхшы.

Колхоз председателе иптәш Нәбиуллин чәчүгә эш атларны хәзерләүгә аеруча зур игтибар бирә. Эш атларының барсы да, 72 се да югары көрлектә. Буаз бияләр житкә һәм чисәа урыннарга беркетелеп куелганнар. Терлек азыкларының контроль астына алынган. Авыл хуҗалыгы машиналарына, инвентарьларга, арбаларга һәм башка кирәк-яракларга югары сыйфатлы итеп ремонт ясалган. Колхоз агротехника чараларын үтәгән.

Бу колхозның уңышлы эш үрнәге белән танышканнан соң, делегация „Яңа Тормыш“ колхозының чәчүгә хәзерлеген тикшерде. Бу колхозда эшләр бөтенләй башкача тора. Колхоз әле дә орлык чистарту эшен тәмамламаган. Ат эшләре чәчүгә хәзерләнмәгән. Машиналар ремонтлап чыгып бетмәгән, атларны чәчүгә хәзерләү буенча да конкрет чаралар күрелмәгән. Колхоз арасында социалистик ярыш тиешенчә оештырылмаган.

К. Исламов.

ХАТЫН-КЫЗЛАРНЫҢ ТРАКТОР БРИГАДАСЫ

Кукмара районының Янил МТС ында хатын-кызлардан трактор бригадасы оештырылды. Бригадага стахановчы тракторчы иптәш Федорова җитәкчелек итә. Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашкан иптәш Гайнуллина бригадир ярдәмчесе итеп билгеләнде.

Тракторларның, тагылма машиналарның һәм заправка инвентарьларын ремонтлау тәмамлангач, бригада тракторларын һәм тагылма машиналарын үзенә беркетелгән участокларга күчерү эшен тәмамлады. Социалистик ярыш договоры төзелде. (ТатТАСС).

Язгы чәчү алдыннан. Лаеш районының „Путь Ленина“ һәм „Победитель“ колхозлары язгы чәчүне иң яхшы үткәрү өчен социалистик ярыш договоры төзеделәр. РӘСЕМДӘ: „Победитель“ колхозчылары „Путь Ленина“ колхозында сынау чыгышындагы чәчү машинасын карыйлар.
С. Чиколкин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

Договорны тикшергәннән соң

Кайбыч районының „Магариф“ колхозы „Единство“ колхозы белән ярыша.

Күптән түгел ике арадагы ярыш договорының үтәлеше тикшерелде. Тикшерү вакытында „Единство“ колхозында язгы чәчүгә хәзерлек буенча аерым кимчелекләргә юл куелганы ачыкланды. Ул вакытта кышкы агротехника чараларын үткәрү үз агымына куелган иде. Кар тоту планы 60 процент, көл җыю планы 43, кырга тирес чыгару—58 процент кына үтәлгән иде. Ремонтланган сабаннарның 7 сен һәм 16 сука камытын начар сыйфатлы ремонт ясалганлыктан, ремонтка кабат кертергә туры килде. Колхозчылар арасында агитация эшләренең бик йомшак булуын күрсәтте. Югарыда күрсәтелгән житешсезлекләрне бетерү буенча делегация эшлекле тәкдимнәр биреп калдырган иде.

Делегациянең тәкдимнәренә „Магариф“ колхозы правлениесе зур әһәмият бирде, күрсәтелгән житешсезлекләрне ашыгыч бетерү өчен конкрет чаралар күрелде. Нәтиҗә начар түгел. Җирле ашламалар хәзерләү эшендә сизелерлек борылыш ясалды. Ремонт сыйфаты начар дип табылган сабаннарга һәм камытларга яңадан ремонт ясалды һәм комиссия тарафыннан кабул ителде. Бригадаларда социалистик ярыш җәелдерелде. Агротехника укулары план буенча уздырыла. Чәчүлек орлыкларның саклануы җентекләп тикшерелә.

Шулай да әле масса-аңлату эшләренең торышы канәгатьләнерлек түгел. Кимчелекләрне бетерү өчен колхоз правлениесенә комсомолның башлангыч оешмасы да эшлекле булышлык итәргә тиеш.

Ю. Фирушин.

Яровойлаштыру иген уңышын күтәрә

Чәчү орлыгын яровойлаштыру агротехника кагыйдәләренә туры китереп үткәрелгәндә яхшы нәтиҗә бирә. Моны без үз тәҗрибәбездә күрдек.

Үткән ел 30 гектар бәрәңгенең 5 гектарын яровойлаштырып утырткан идек. Яровойлаштырып утырткан участокта һәр гектардан 35 центнер, ә яровойлаштырылмаган участокта 18,3 центнер уңыш чыкты.

Без бәрәңге орлыгын сәндерәләргә таратып салу юлы белән яровойлаштырабыз. Бәрәңге орлыклары 12—13 градус җылылыктагы бинада 40—45 көн тотылды. Бәрәңгене яровойлаштырган вакытта аны әйләндереп тору зур әһәмияткә ия. 3—4 көн саен бәрәңгене әйләндереп торырга кирәк. Шулай итмәгәндә, бәрәңге орлыгының күләгәдә яткан күзәнәкләре ак төстә, зәгыйф, озын булып үсәләр һәм алар утыртканда вакытта сынып имгәнеп бетәләр. Моңа юл куймаска кирәк.

Бодай орлыгын яровойлаштырып чәчү дә шулай ук яхшы нәтиҗәләр бирде. 232 гектар бодайның яровойлаштырып чәчкән участокның яровойлаштырылмыйча чәчкән участокка караганда һәр гектардан 4,27 центнер уңыш артык чыкты.

Без быел 10 гектар бәрәңгене яровойлаштырып утыртабыз һәм барлык бодай культурасын яровойлаштырып чәчәбез. Моның өчен кирәкле биналарны хәзерләдек. Бәрәңге орлыгын сәндерәләргә таратып салдык. Алдан 24 яровизатор хәзерләдек. Бәрәңге орлыгын яровойлаштыруга шушы көннәрдә керешәбез.

М. Галимов.

Актаныш районы, „Үрнәк“ колхозының агротехнигы.

Матбугат күзәтү урнында

МӨҺИМ МӘСЬӘЛӘДӘН ЧИТЛӘШКӘН ГАЗЕТАЛАР

Республикабызның Теләче районы колхозлары чәчү орлыклары белән колхозара ярдәм оештыру турында бик яхшы инициатива башлап жибәрделәр. Беренче буларак, бу районның „Кызыл Ямбулат“ колхозы чәчү орлыгы җитми торган „Төрекбаш“ колхозына 600 центнер орлык биреп торырга карар бирде. Аның артыннан „Кремль“, „Чулпан № 2“, „Марс № 1“ һ. б. колхозлар үзләреннән арткан орлыкларны үзара ярдәм тәртибендә башка колхозларга күтәргә бирү турында бер-бер артлы карар кабул иттеләр. Шулай итеп, берничә көн эчендә шушы юл белән районда 5.740 центнер чәчү орлыгы тупланды.

Бу хәбәр республикабызның башка районнарына да яшен тизлеге белән таралды. Колхозчылар бу гүзәл инициативаны кайнар рәвештә каршы алдылар һәм орлык туплауда барлык эчке байлыклардан файдалану өчен конкрет чаралар күрә башладылар.

Район газеталары бу гүзәл башлангычны вактында тотып алырга, аны оештыруда партия, совет оешмаларына, җир органнарына ярдәм итәргә тиешләр иде.

Бу өлкәдә үзенең бурычларын дөрес аңлаган газеталар шулай эшләделәр һәм эшлиләр дә. Ләкин кайбер районнарның газеталары бу мәсьәләдән бөтенләй читтә торалар, орлык туплау, колхозара орлык алмаштыру, орлык белән үзара ярдәм оештыру, орлык чистарту кебек көннең кадагы булган мәсьәләләрне читләтеп узалар.

Ютазы районында чыга торган „Коммунизмга“ газетасын нак менә шундыйлар рәтенә кертергә мөмкин.

Бәлки бу районда бөтенесе дә ал да-гөлдер, бәлки бу мәсьәлә инде бу район өчен көннең кадагы булудан төшеп калгандыр? Һич тә алай түгел. Моны газетаның редакторы Зиннәтуллин, аның урынбасары Әхмәтҗанов иптәшләр генә шулай уйлыйлар булса кирәк. Фактта исә орлык туплау мәсьәләсе бу районда үтә кискен хәлдә тора.

Районда 16.640 центнер орлык җитми. Колхозлар бу орлыкны үз эчләреннән табарга, эчке байлыклардан, эчке мөмкинлекләрдән файдалану исәбенә тупларга тиешләр. Газета бу эшне оештыруда колхозчыларга, колхоз правлениеләренә, партия, совет оешмаларына якыннан булышлык итәргә, аларга дөрес юнәлеш бирергә, бу өлкәдәге яхшы үрнәкләрне күрсәтүне оештырырга тиеш иде. Кызганычка каршы газета моны эшләми.

Чәчү орлыгы җитмәгән колхозларда аны җиткерү өчен нинди чаралар күрелә, колхозлар арасында орлык белән ярдәмләшү буенча нәрсә эшләнә, кайсы колхозлар яхшы үрнәк күрсәтәләр, бу эшкә колхозчылар ничек катнашалар, район җир бүлеге, МТС работниклары колхозларга ничек җитәкчелек итәләр—бу турыда газетаның 23 нче февральдән соңгы номерларында бер генә нәрсә дә күрмибез. Шуннан соң, бер генә нәтиҗә ясарга кала: „Коммунизмга“ газетасы редакциясендә эшләүче иптәшләр районда орлык туплауның нинди хәлдә булуын белмиләр яки белергә дә теләмиләр.

Чәчү орлыклары туплау мәсьәләсендә үзләрен нейтраль тотучылардан тагын Кайбыч районында чыга торган „Колхоз бригадасы“ газетасын күрсәтергә кирәк. Бу газетаны авыл хуҗалыгы турында, аерым алганда язгы чәчүгә хәзерлек турында язмый дип булмый. Аның битләрендә бу темаларга язылган материалларны еш кына очратырга була. Ләкин бу материалларны укыгач, газета язгы чәчүне орлык җитәрлек булмаса да үткәрергә мөмкин дип саный күрәсең, дигән нәтиҗәне ясыйсың. Чөнки орлык хәзерләү, орлык белән үзара ярдәм турында ул материалларда һәм гомумән газетада бер җөмлә дә табып булмый. Газетаның 13 нче февраль номерында „Гектардан йөз пот иген уңышы алу өчен!“ дигән баш мәкалә урнаштырылган. Шушындый яңгыравыклы баш астында язылган мәкаләдә, бигрәк тә сүз һәр гектардан 100 пот уңыш өчен көрәш турында баргач, чәчү орлыгы турында ләм-мим булмавына газетаны укучылар гаҗәпләнгәннәрдер, әлбәттә. Ләкин аңа карап газетаның редакторы иптәш Нәҗметтинов үзенең дәшмәүчелек позициясен барыбер үзгәртмәгән. Ул хәзер дә шушы позициядә нык тора. Моны раслау өчен газетаның соңгы 11 номерында орлык турында бер генә мәсьәләнең дә күтәрелмәвен күрсәтү дә җитә. Сүз уңаена редакциянең исенә төшереп үтик, Кайбыч районында да колхозара ярдәм тәртибендә тупланырга тиешле 1.675 центнер орлыкның әле бары 600 центнеры гына тупланган.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк, Кайбыч район газетасы редакциясе дә, Ютазы район газетасы редакциясе дә үзләренең бу позицияләрен үзгәртергә, ә бирелдә эшләүче иптәшләр совет работникларына гына хас булган югары сыйфатны—мөһим мәсьәләне вактында эләктереп ала белү сыйфатын онытмаска тиешләр. Моны эш таләп итә, партия, совет оешмалары һәм бөтен җәмагатьчелек таләп итә.

М. Хәмит.

ТӨЗҮ МАТЕРИАЛЛАРЫ ҖИТЕШТЕРҮНЕ ТАМЫРЫННАН ЯХШЫРТЫРГА

Партиянең XVIII нче съезды төзү материаллары промышленностен барлык чаралар белән үстерү бурычын куйды. Тарихи съездның бу карарын үтәү, күп санда һәм югары сыйфатлы төзү материаллары эшләп чыгару буенча Татарстан Совнаркомы янындагы төзү материаллары промышленносте идарәсе әлегә кадәр кискен борылыш ясаганы юк.

Төзү материаллары промышленносте идарәсе предприятиеләре 1939 нчы елны тулай продукция җитештерү планын бары 68,9 процент кына үтәделәр. Үткәндәге җитешсезлекләр быел да кабатланалар. Январь ае планы бары 71,3 процент, февраль ае планы 79,8 процент кына үтәлде. Март аенда да эш канәгатьләнерлек түгел.

„Строитель“ кирпеч комбинаты бер генә вакытны да үзенең планын тулы үтәгәне, югары сыйфатлы продукция эшләп чыгарганы юк. Комбинат җитәкчеләре производство мәсьәләләре белән очраклы рәвештә генә шөгыльләнәләр, зур кимчелекләрне теркәп кую белән генә чикләнәләр. 14 нче кирпеч заводын төзү күптәннән төгәлләнергә тиеш иде инде. Бу төзелеш шушы елның беренче кварталында да төгәлләнмәде. Прессларны монтажлау аеруча артка калып бара. Технология җиһазларын яңа баштан кору эше тирән өзеклектә. Югары вольтлы электр чыбыклары өчен баганалар әлегә кадәр төзелеш мәйданына китерелмәгән. Комбинат директоры Игнатов, баш инженер Рыбин һәм төзелеш начальнигы Шебаршов иптәшләр 14 нче кирпеч заводын төзү буенча тиешле инициатива һәм тырышлык күрсәтмиләр.

Комбинат җитәкчеләре производство планының үтәлмәвенә, еш кына хәлләрдә, объектив сәбәпләр табарга маташалар. Ләкин бу һич тә дөрес түгел. Яхшы сыйфатлы продукция җитештерү өчен мөмкинлекләр зур. Эшчеләр коллективы үз бурычын үтәүгә һәр вакыт хәзер тора. Игнатов, Рыбин һәм башка иптәшләр производство алдынгыларының эш үрнәкләрен, яңалыкны башлап йөрүләрен күреп җиткермиләр. Аларга тиешле һәм уңайлы эш шартлары тудыру буенча ныклы чаралар күрелми. Шунлыктан кайбер стахановчылар һәм квалификацияле работниклар производстводан китәргә мәҗбүр булалар. Иптәш Носов мәсьәләсен алып карыйк. Комбинатта ул 6 ел буе өзлексез эшләп килде. Ул мастер булу дәрәҗәсенә кадәр үсеп, кирпеч яндыруда югары үрнәкләр күрсәтте. Комбинат җитәкчеләренең аңа эш шартлары тудырмаулары нәтиҗәсендә, ул быел комбинаттан китте.

Производство алдынгыларының тәҗрибәләрен башкаларга күчерү турында дирекция дә, партия һәм профсоюз оешмасы да гадәттән тыш аз кайгырталар. 2 нче номерлы пич стахановчысы иптәш Хәбибуллин яңа норманы 185 процент итеп үти. Ул үз эшендә зур тырышлык һәм инициатива күрсәтә. Токарь иптәш Портнов норманы 320 процент, күмер ташучы иптәш Маннанов 250 процент итеп үтиләр. Ләкин Хәбибуллин, Портнов һәм Маннанов иптәшләрнең үрнәкле эшләрен комбинатның башка эшчеләре бик аз беләләр. Аларның тәҗрибәләрен башкаларга күчерү эше белән бер кем дә шөгыльләнми.

Эшсез торуларның да зур булуын әйтергә кирәк. Администрация гаебе буенча эшсез торулар бик еш кабатлана. Бу тәртипсезлеккә чик кую һәм эшсез торуларны бетерү өчен комбинат җитәкчеләре конкрет чара күрмиләр.

Эшчеләрнең культура һәм көнкүреш шартларын яхшыртуга, торак төзелешенә һәм башкаларга һәр ел саен дәүләт тарафыннан зур сумалар җибәрелә. Төзү материаллары җитештерүче предприятиеләр бу эшкә шактый зур күләмдә акча алалар. Ләкин средстволарны урынлы тоту өчен көрәш һич тә җитәрлек түгел. „Строитель“ кирпеч комбинатында стахановчылар һәм производство алдынгылары өчен ике торак йорты төзүне төгәлләү турында Игнатов һәм Рыбин иптәшләр күп тапкырлар вагдә бирделәр. Бу йортларны төзүнең соңгы срогы итеп алар 15 нче февральне билгеләделәр. Менә февраль ае үтеп китте. Инде март ае да үтеп бара. Ә төзелеш планы һаман да 73 процент кына үтәлгән килеш тора.

Бимәр карьерасында хезмәтне дөрес оештыру, стахановчыларга булышлык итү, алдынгыларның тәҗрибәләрен производствоның барлык эшчеләренә күчерү буенча бик йомшак эшлиләр. Карьера җитәкчеләре үз бурычларын үтәүгә һаман да әле якын килә алганнары юк.

Промышленностьның башка тармакларындагы кебек үк төзү материаллары җитештерүче предприятиеләрдә дә социалистик ярыш яхшы нәтиҗәләр бирә. Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү буенча өченче бишьеллыкны дүрт елда үтәү өчен Москва инструментальчыларының чакыруларына төзү материаллары җитештерүче предприятиеләрнең алдынгылары эш белән җавап бирәләр. Ә безнең төзү материаллары предприятиеләрендә бу хәрәкәткә җитәкчелек итү һич тә канәгатьләнерлек түгел әле. Төзү материаллары промышленносте идарәсенең үзендә дә, аның предприятиеләрендә дә социалистик ярышка җитәкчелек эше еш кына хәлләрдә формаль рәвештә алып барыла. Казан известь заводында (директоры иптәш Кузьмин), Чистай заводында (директоры иптәш Федоров), Бимәр карьерында (директоры иптәш Хөснеттинов) социалистик ярыш үз агымына куелган. Бу предприятиеләрнең җитәкчеләре хәтта үзләрендә күпме стахановчылар, ударниклар барлыгын да ачык әйтә алмыйлар. Җитәкче работниклар стахановчылык хәрәкәтенә булышлыкны бөтен чаралар белән яхшыртырга һәм продукция җитештерү буенча кискен борылыш ясарга тиешләр.

Төзү материаллары җитештерү буенча продукциянең эшләнү бәясе шактый кыйммәткә төшә. Күпчелек предприятиеләр артык расходлар тотуга, дәүләт средстволарын әрәм-шәрәм итүгә юл куялар. Үткән елны продукциянең эшләнү бәясе буенча 1 миллион 151 мең сум акча артык тотылды. „Строитель“ комбинаты ягулык буенча гына да 102 мең сум артык расход ясады. Комбинат беренче сорт кирпеч эшләп чыгару буенча әлегә кадәр конкрет бер чара да күргәне юк. Продукциянең түбән сортлы булуы нәтиҗәсендә комбинат 141 мең сум артык расход тотты. Башка предприятиеләр буенча да мондый фактлар аз түгел. Хезмәт хакы фондын артык тотулар еш кабатлана. Үткән елны бу тармакта барлыгы 244 мең сум артык расход тотылды.

Безнең республикабызда җирле ягулык запасы бик зур. Ләкин аны хәзерләүгә аз игтибар бирелә. Районнардагы предприятиеләр аеруча артка калып баралар. Алар 13.827 кубометр утын урнына бары 1.950 кубометр гына хәзерләделәр. Зеленодольски заводы директоры Капралов һәм Васильево заводы директоры Куряков иптәшләр утын ташу эшен оештырмаганнар. Сатып алынган 5.300 кубометр утынның бер генә кубометры да заводка китерелмәгән. Чаллы һәм Буа кирпеч заводлары утынны 30 километр ераклыктагы урманнан ташыйлар, ә заводтан 4 кенә километр ераклыктагы торфтан файдаланмыйлар. Әгәр дә алар торфны утын урнына дөрес файдаланган булсалар, шактый зур экономия ясый алырлар иде.

Арча, Васильево, Чистай, Мамадыш, Аксубай, Ширәмәт һәм Зеленодольски заводларында да утын урнына торфтан файдалану өчен зур мөмкинлекләр бар. Бу заводларда ягулыкның 50 процентын гына торфка күчергәндә дә 232 мең сум экономия ясап булачак. Шуның белән бергә транспортны да ерактан утын ташудан бушатырга мөмкин булачак.

ВКП(б) райкомнары һәм башкарма комитетлары төзү материаллары предприятиеләренең эше белән аз кызыксыналар. Партиянең Юдино, Биектау һәм Киров райкомнары үткән елны директорларның докладларын бер тапкыр да тыңламадылар. 1940 нчы елгы сезонга хәзерлекнең барышы турында да район предприятиеләре директорларының докладлары райком һәм район башкарма комитетлары утырышларында тыңланмый. Ә кирпеч заводлары сезонга бик начар хәзерләнәләр. 51 киптерү сараена ремонт ясалырга тиеш иде, ә бары 21 сарайга гына ремонт ясалган. 40 пичнең бары 8 е генә хәзерлек хәленә китерелгән.

Партиянең Татарстан оешмасының XXI нче өлкә конференциясе төзү материаллары промышленносте җитәкчеләрен каты тәнкыйть итте. Өлкә матбугатында да бу турыда сигналлар булды. Без бу күрсәтмәләрдән җидди нәтиҗәләр ясарга, җитешсезлекләрне бетерү өчен барлык чараларны күрергә һәм төзү материаллары җитештерүче промышленностьны алдынгылар сафына чыгарырга тиешбез.

Төзү материаллары промышленносте идарәсе Акинский руднигын һәм Бимәр карьерын бергә кушуны кирәкле дип тапты. Бу эштән шактый зур экономия булачак. Язгы ташкын вактында Волга һәм Казанка елгалары буенча Казандагы известь-алебастр заводына су транспорты белән 9.000 тонна алебастр ташы китерү билгеләнде. Бу эштән дә зур экономия булачак. Татарстан Совнаркомы мондый чараларны үткәрүгә практик булышлык күрсәтергә тиеш.

Төзү материаллары промышленносте Татарстанның 20 еллыгына ярты еллык планны үтәү һәм арттырып үтәү өчен Чувашстанның төзү материаллары промышленносте белән социалистик ярышка чыкты. Без ике республика арасында төзелгән ярыш йөкләмәләрен тулы үтәргә тиешбез. Күп санда һәм югары сыйфатлы төзү материаллары җитештерү өчен республикабызда гаять зур мөмкинлекләр бар. Төзү материаллары промышленносте идарәсендәге, шулай ук аның предприятиеләрендәге җитешсезлекләрне ашыгыч бетерергә, промышленностьның бу әһәмиятле тармагында хезмәт җитештерүчәнлегенең яңа күтәрелешен тудырырга тиешбез.

Королев.

Чит илләрдә

КЫЗЫЛ АРМИЯ ТУРЫНДА ШВЕЦИЯ „ДОБРОВОЛЕЦЛАРЫ"

СТОКГОЛЬМ, 23 март. (ТАСС). Швециядә чыга торган „Ню даг" газетасы Швециянең Финляндиядәге сугышларда катнашкан „доброволецлары"ның Кызыл Армия турындагы фикерләрен басып чыгара.

Газета болай яза: „Швециянец" доброволецлар корпусы" Финляндия фронтына килеп җиткәч, монда данлыклы шведлар турында һәм русларның аларга каршы тора алмаячаклары турында төрле хәбәрләр тарата башладылар. Ләкин солых төзелү бу әкиятләрнең барсына да чик куйды. Фронттан кайтучы швед доброволецлары „утны туктатырга" команда бирелгәч барлык шведларның шатланганлыклары турында сөйлиләр. Походта катнашучыларның берсе болай ди: „Солыхның вактында төзелүе чыннан да зур бәхет булды. Без Маннергейм линиясен Кызыл Армиянең өзгәнлеген дә белмәдек. Безне һәр вакыт алдадылар". „Ню даг" газетасы болай дип яза: „Швед һәм фин солдатлары Кызыл Армиягә каршы сугышлардан соң Совет армиясе турында буржуаз һәм социал-демократ газеталарының ялган хәбәрләре буенча үзләрендә тупланган фикерләрен үзгәртергә мәҗбүр булдылар. Кызыл Армиянең батырлыгы, чыдамлыгы һәм сугыш сәләте аларны бик нык гаҗәпләндерде". Доброволецлар болай диләр: „Бездә русларның хәрәкәтенә каршылык күрсәтергә бер нинди мөмкинлек юк иде. Без хәтта ата да алмадык һәм котылыр өчен карга күмелдек". Күп кенә доброволецлар болай дип сөйлиләр: „Без моннан соң бер кайчан да Кызыл Армиягә каршы чыкмабыз. Без Кызыл Армиянең коралы начар дип уйлаган идек, ләкин без бу коралның көченә ышандык. Без руслар авиациясе начар дип уйлаган идек, ләкин безнең истребительләрнең тизлеге русларның бомбардировщиклары тизлегеннән 100 километрга кимрәк икән. Русларның истребительләренә килгәндә исә без андый тизлекне һәм төгәллекне күргәнебез юк иде".

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

НЬЮ-ЙОРК, 23 март. Юнайтед Пресс агентлыгының Уэллесны АКШ та Италиянең „Конте ди Савойя" пароходында озата баручы хәбәрчесенең хәбәр итүенә караганда, Англия властьлары Германия финансисты Шахтны эзләп Гибралтарда бу пароходны 13 сәгатькә тоткарлап торганнар.

БЕРЛИН, 23 март. Информация бюросының хәбәр итүенә караганда, 20 нче мартта Шотландия ярлары якынында Даниянең 3.270 тонна авырлыгындагы „Христиансборт" пароходы баткан. Команданың бер матростан башкасы тулысынча коткарылган. Шушы пароход батырылу белән соңгы 2 көн эчендә Дания сәүдә флотының югалтуы барлыгы 10.548 тонна авырлыктагы 6 пароходка җитә.

ПАРИЖ, 23 март. Кичә фронтта берниндн дә яңалык булмаганлык турында рәсми рәвештә хәбәр ителә. Төнлә Саар елгасыннан көнчыгышта патрульләрнең активлыгы сизелгән.

БЕРЛИН, 23 март. Германия армиясенең верховный командованиесе хәбәр итә: „Көнбатыш фронтта берниндн әһәмиятле вакыйга булмады. Дошманның зенит артиллериясеннән көчле ут алып баруына һәм истребительләр авиациясенең хәрәкәтләренә карамастан, кичә Германия самолетлары Франция өстендә разведка ясадылар. Германиянең көнбатыш чиге өстендә дошманның берничә разведка самолеты очты. Клеве районында Германия истребителе Англия самолетын бәреп төшерде. 22 нче мартта һәм 23 нче мартка каршы төндә дошманның самолетлары Голландиянең, Бельгиянең һәм Люксембургның нейтралитетын боздылар.

ЛОНДОН, 23 март. Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, кичә Лобит якынында (Голландия) Англиянең 4 самолеты белән Германиянең 7 самолеты арасында сугыш булган. Англиянең 3 самолеты зур югарылыкка күтәрелгән, ә дүртенчесе Германиянең 3 самолеты тарафыннан чолгап алынып, бәреп төшерелгән һәм Вааль елгасына төшкән. Аның экипажы әле табылмаган. (ТАСС).

Франциянең яңа хөкүмәте турында Англия матбугаты

ЛОНДОН, 23 март. (ТАСС). Газеталар Франциянең Рейно җитәкчелегендәге яңа хөкүмәтенең властьта озак тора алуына беркадәр шикләнү белдерәләр. Шуның белән бергә, укучыларның настроениесен күтәрү өчен, „Дейли Телеграф энд Морнинг Пост" һәм „Ньюс кроникл" газеталары Рейно хөкүмәтенең язмышы нинди булачагына да карамастан, Франциянең сугышны җиңгәнгә кадәр дәвам иттерергә теләвен белдерәләр.

„Таймс" Рейно хөкүмәтенә Англиянең авторитетлы даирәләренең симпатиясен күрсәтеп үтә һәм элекке баш министр Даладьене нык тәнкыйт итә. Үткән атнада Франциядә хөкем сөргән настроениеләрне характерлап, газета болай дип яза: „Даладье хөкүмәтенең инициатива күрсәтергә үзенең сәләтсез икәнлеген күрсәткәнлеге сизелә иде. Кабинетны үзгәртеп кору котылгысыз иде, чөнки пассив каршылык күрсәтү методлары белән сугышта отарга мөмкин түгеллек ачык булып әверелде".

ИСПАНИЯДӘГЕ ХӘЛЛӘР

Англиянең „Экономист" журналы Испаниянең төньяк чиге буенда ныгытмалар линиясе барлыкны хәбәр итә. Пиреней тауларының Баск өлешендә моннан 18 ай элек төзелгән ныгытмаларны Каталония чигенә кадәр сузу эшләре бара. Бу эш- [illegible] Сугыш вакытында бер миллион чамасы кеше үтерелүе, 400 мең кешенең сөргендә булуы һәм 1 миллион чамасы кешенең концентрация лагерларында булуы сәбәпле Испаниянең промышленностенда һәм авыл хуҗалыгында гаять күп санда эшчеләр җитешми. Каталония промышленносте бөтенләй таркау хәлдә. 23 март. (ТАСС).

СОФИЯДӘ СОВЕТ САМОЛЕТЫН ТАНТАНАЛЫ КАРШЫ АЛУ

СОФИЯ, 24 март. (ТАСС). Москва—София юлы буенча беренче рейс самолеты Софиягә килгәнче үк Божурище аэродромында халык җыела башлаган. [illegible]

СОВЕТ САМОЛЕТЫНЫҢ СОФИЯГӘ ОЧЫП КИЛҮЕ ТУРЫНДА БОЛГАРИЯ МАТБУГАТЫ

СОФИЯ, 24 март. (ТАСС). Москва—София юлы буенча беренче рейс самолетының Болгариянең башкаласына очып килүе турында Болгарияның бөтен матбугаты хәбәр итә. [illegible]

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА. [illegible]

ҮЗӘК КЫТАЙДА. [illegible]

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА. [illegible]

Шоферлар хәзерләү—җаваплы бурыч

Автотранспорт өчен шоферлар хәзерләү — әһәмиятле бурычларның берсе. Ләкин республикабызда бу эшнең торышы канәгатьләнерлек түгел. Автомәктәпләрдә һәм курсларда шоферлар хәзерләү буенча Татарстан Совнаркомы билгеләгән планның 88 процент кына үтәлүе моның шулай икәнлеген ачык күрсәтә. Татарстан Осоавиахим оешмасының автомәктәбе планны бары 12,5 процент кына үтәде.

Физкультура-Спорт Комитеты һәм башка оешмалар янындагы автомәктәпләр любитель-шоферлар хәзерләү эшенә игтибар бирмиләр. Алар шоферлар хәзерләү планын бары 29 процент кына үтәделәр. Республикада хатын-кызлардан автотранспорт өчен кадрлар хәзерләү эше бигрәк тә начар тора. Татарстан Совнаркомының карары буенча автомәктәпләрдә һәм курсларда укучыларның иң кимендә 50 проценты хатын-кызлар булырга тиеш иде. Ләкин автомәктәпләрне тәмам итеп чыккан шоферлар арасында хатын-кызлар 0,05 процент кына тәшкил итә.

Мәктәпләрдә укуның сыйфаты түбән. Шуның нәтиҗәсендә, укучыларның зур гына өлеше Дәүләт автоинспекциясендә имтихан тота алмыйлар.

Автомобильне йөртү техникасы һәм автомобиль төзелеше дәресләре белән эш аеруча начар тора. Имтихан тота алмаучыларның 35 проценты автомобиль йөртү техникасы дәресе буенча, 42 проценты автомобиль төзелеше дәресе буенча сынаудан үтә алмадылар.

Дисциплинаның тиешле югарылыкта булмавы да укуның сыйфатына начар йогынты ясый. Татарстан Совнаркомы янындагы Автотранспорт идарәсе мәктәбендә (директоры иптәш Чеботарев) дисциплинасызлык аеруча урын алган. Укытучылар ныклы дисциплина өчен көрәшмиләр. Автотранспорт идарәсе хөкүмәтнең кыска сроклы курсларда автомобиль йөртүчеләр хәзерләү турындагы карарының үтәлешен тикшерми. Бу тармактагы зур кимчелекләрне ашыгыч бетерергә, шоферлар хәзерләү планын төгәл үтәргә кирәк.

Войтович.

Совет радио тапшыруының унбиш еллыгына карата. Бөтенсоюз радио комитеты (Москва) студиясендә. РӘСЕМДӘ: „Соңгы хәбәрләр" тапшыру. Микрофон янында дикторлар Н. А. Толстова һәм Ю. Б. Левитан иптәшләр.

А. Грибовский фотосы (ТАСС фотохроникасы).

НАВИГАЦИЯГӘ ХӘЗЕРЛЕК

Казан пристанендә һәм аның карамагындагы затоннарда навигация ачылуга хәзерлек бара.

Казан пристане идарәсенең су трамвайлары „Красный Волгарь" затонында, буксир пароходлары, дебаркадерлар һәм баржалар Аракчино затонында кышладылар. Пристань начальнигы иптәш Орлов навигациягә хәзерлекнең барышы турында болай ди:

— Су трамвайларын ремонтлау планы 10 нчы мартка 80 процент, дебаркадерларны һәм баржаларны ремонтлау—уртача 78 процент, буксир пароходларны ремонтлау—93 процент үтәлде. Механизмнарны төзәтү һәм столярлык эшләре төгәлләнде. Хәзер судноларны буяу һәм җиһазлау эшләре бара. Казан белән Красновидово арасында йөрү өчен билгеләнгән „Мартьянов" пароходына Горький өлкәсенең „Парижская Коммуна" затонында капиталь ремонт ясала.

Пароходларга товар төягәндә һәм бушатканда транспортерларны хәрәкәткә китерә торган 64 моторның 59 ына, 10 транспортерның 9 ына ремонт тәмам булды.

Йөкләрне пароходлардан вагоннарга кадәр транспортерлар ярдәме белән күчерү өчен быел өстәмә механизмнар ясала. Аргы Усиягә йөзмә ике вокзал һәм берничә дебаркадер куелачак. Җирле пристаньнарга йөри торган пароходлар туктый торган вокзал янында пассажирлар өчен яр буе вокзалы төзелә. Вокзалларда ике ресторан, ике буфет эшләячәк.

Судноларга, лабазларга һәм механизмнарга ремонт ясауга 800 мең сум акча җибәрелде.

1940 нчы елгы навигация сезонында Казан пристане аркылы товар җибәрү өчен договорлар төзү тәмам булды. Зур тизлек белән 178 мең тонна, кечкенә тизлек белән 56 мең тонна товар җибәреләчәк һәм 156 мең тонна авырлыгындагы саллар буксир пароходлар белән китереләчәк. Беренче пароходлар белән җибәрү өчен билгеләнгән товарлар Аргы Усиягә ташылып куелды. Быел Волганың урта агымында апрель ахырларында навигациянең ачылуы көтелә.

Су трамвайлары Казан—Түбән Ослан, Казан—Шеланга, Казан—Красновидово һәм Казан—Зөя маршрутлары буенча йөреп торачаклар. Горький—Казан—Астрахань арасында 4 линия эшләячәк. Горький—Казан—Молотов, Рыбински—Горький—Казан—Молотов арасында һәр көн икешәр пароход йөреп торачак. Вятка пароходлары Казан белән Киров арасында йөреп торачаклар. Уфа пароходлары баштарак Казанга кадәр, аннары Москвага кадәр барачаклар. Казан белән Тәтеш арасында товар йөртү өчен Казан пристане идарәсе карамагына ике баркас бирелә.

Судноларның командаларына 15—20 нче апрельгә кадәр үзләренең билгеләнгән урыннарына килеп җитәргә тәкъдим ителде.

Г. Латыйпов.

ХУДОЖЕСТВО ҮЗЕШЧӘНЛЕГЕ СМОТРЫ

Юдино районы мәктәпләрендә балаларның художество үзешчәнлегенә смотр башланды. Районның 12 мең укучы пионерлары балаларның район күләмендәге художество иҗады олимпиадасында катнашу өчен актив рәвештә хәзерләнәләр.

Васильеводагы урта мәктәпнең 7 нче классында укучы Груздова смотрда танкистлар турындагы җырны, 8 нче класс укучысы Турова чегән биюен яхшы башкардылар.

Васильеводагы тулы булмаган урта мәктәптә дә смотр уңышлы үтте. Укучы Капшицер М. Горькийнең „Давыл хәбәрчесе турында җыр" дигән әсәрен сөйләде. Укучылардан Носкова һәм Бикмуллина татар биюе „Әпипә"не яхшы башкардылар.

(ТатТАСС).

ТАТАРСТАНДА

Минзәлә районындагы Мактавыш МТС ының барлык 12 трактор бригадасы үз участкыларына киттеләр. Тракторчылар үзара социалистик ярыш договоры төзеделәр. Долгов һәм Ибатуллин иптәшләр трактор белән меңәр гектар эшләргә йөкләмә алдылар. Бригадалар тракторчылар кадрлары белән тулысынча тәэмин ителде.

* * *

Татарстан Сәламәтлек Саклау Халык Комиссариаты быел язгы чәчү вакытында колхозчыларга медицина ярдәме күрсәтүне көчәйтү өчен районнарга 25 врач җибәрә. Алар участкы больницаларында эшләячәкләр.

* * *

Лаешның саго заводы Столбище һәм Лаеш районнарында торф чыгаруны оештыра. Бу эшкә быел 455 мең сум акча тотылачак.

* * *

Шушы елның 1 нче январеннан 20 нче мартына кадәр Казандагы саклык кассалары дәүләт заемнары буенча хезмәт ияләренә 786 мең сум отыш түләделәр.

* * *

Татарстан Урман Промышленносте Халык Комиссариаты предприятиеләренә быел 900 мең сум капитал салына. Бу акчага газогенераторлы автомобильләр алыначак, урман кисү эшендәге эшчеләргә күчмә тораклар, ашханәләр, тулай тораклар һәм башка биналар төзеләчәк.

* * *

Казан аэроклубы очучылар курсларына курсантлар алуны төгәлләде. Курсантлар производстводан аерылмыйча өйрәнәчәкләр. Студентлардан, урта мәктәп укучыларыннан, Ленин исемендәге заводның һәм башкаларның яшь эшчеләреннән меңнән артык гариза алынган иде. Курсларда теоретик занятиеләр башланды.

Балаларның гимнастика ярышлары

Бүген Менжинский исемендәге клубта балаларның гимнастика ярышлары башлана. Ярышларда Архангельский, Киров, Молотов, Свердловски, Горький, Куйбышев, Магнитогорский, Чиләбе, Уфа, Ижевски, Чебоксар һәм Казан шәһәрләреннән барлыгы 216 бала катнашачак.

Бу шәһәрләрнең командалары арасында узган ел Свердловскида булган ярышларда Казан командасы беренче урынны алып, Бөтенсоюз ярышларында катнашу хокукын алган иде. Казанның 15 нче номерлы мәктәбе укучысы Давыд Кренин гаять зур уңыш казанып, куст чемпионы дигән исемне алган иде.

Казан командасы быелгы ярышларга да зур гына хәзерлек алып барды. Хәзерлек эшенә тәҗрибәле тренерлардан Липатов, Усов, Шенгелая һәм Парай-Коши иптәшләр җитәкчелек иттеләр.

Ярышлар 28 нче мартта тәмам булачак.

А. М. ГОРЬКИЙ КИЧӘСЕ

Казан Укытучылар йорты пролетариатның бөек язучысы Алексей Максимович Горькийның тууына 72 ел тулу уңае белән 29 нчы мартта укытучылар өчен Горький кичәсе үткәрә.

Кичәдә бөек художникның тормышы һәм иҗады турында доклад куела. Докладтан соң республиканың халык артистлары Григорьев, Любин, Якушенко һәм артист Мацкевич Горький әсәрләреннән өземтәләр укыячаклар.

Укытучылар йортының китепханәсе үзендә булган китаплардан Горькийга багышланган күргәзмә оештыра.

ЕЛГАЛАРДА

Волга суы тәүлеккә 2—5 сантиметр артуда дәвам итә. Ташу башланганнан алып 25 нче мартка кадәр Вязовые янында 50 сантиметр, Югары Ослан районында 46 сантиметр су артты. Кама суы тәүлеккә 1—2 сантиметр арта. Апрельнең икенче декадасы ахырларында Волганың боздан арчылуы көтелә.

КӨНДӘЛЕК ВАКЫЙГАЛӘР

Җинаятьчеләр эзеннән. Яңа Чишмә районының Екатериновка авылында торучы Н. Шаронов Казанда солы сатарга килгән. Ул үзенең бер йөк солысын Луковский урамындагы 9 нчы йортның амбарына бикләп куйган. Төнлә караклар амбар йозагын ватып кереп, аның 160 килограмм солысын урлаганнар. Бу турыда хәбәр алынгач та, милиция работниклары „Моля" дигән эзләүче эт белән барганнар. „Моля" аларны Тихомиров урамындагы 26 нчы йортта торучы Чуклов дигән кешенең квартирасына алып килгән. Урланган солы Чуклов квартирасында табылган. Бу җинаятьтә гаепләнеп өч кеше кулга алынган.

БЕЛДЕРҮ

26 нчы март, кич 6 сәгатьтә ВКП(б) Өлкә Комитетының Партия Мәгарифе йортында „ВКП(б) тарихының кыскача курсы" ның VII нче бүлегенә карата рус телендә лекция була. Тема: „Кораллы восстание хәзерләүгә карата большевиклар партиясенең курс тотуы. Партиянең VI нчы съезды".

Лектор—иптәш Громов.

Редактор урынбасары И. ҮЗБЕКОВ.
Зам. редактора И. УЗБЕКОВ.

28 нче март, кич 7 сәгатьтә Тире-Венера авырулары клиникасы аудиториясендә Казан Дәүләт Мединституты гыйльми советының ачык утырышы чакырыла һәм медицина фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен врач А. И. Поляцева тарафыннан халык алдында

ДИССЕРТАЦИЯ ЯКЛАУ ҮТКӘРЕЛӘ

Тема: „Үпкәдә һәм үпкә ярыларында җешү процесслары булганда блуждающий нервның төен сыман һәм яремный ганглийләрендәге үзгәрешләр".

Рәсми оппонентлар: атказанган, фән эшлеклесе профессор А. Н. Миславский һәм атказанган, фән эшлеклесе профессор А. Г. Терегулов.

Диссертация материаллары белән Медицина Фәнни Җәмгыятьләре китепханәсендә танышырга мөмкин. 535—1

Язгы ташулар вакытында Казан нефтебазасының 2 һәм 3 нче группаларын су басачак. Шул уңай белән, барлык кулланучыларга апрель—май айлары өчен кирәкле күләмдә

авто-трактор һәм индустрия майларын нефтебазадан шушы ел 15 нче апрельгә кадәр алырга тәкъдим ителә

Авто-трактор һәм индустрия майлары алу өчен, кулланучылар тулысынча чиста хәлендәге савытлар белән килергә тиешләр. 538—1

КАЗАН ФИНАНС-ЭКОНОМИКА ИНСТИТУТЫ

предприятиеләрнең хуҗалык эшләрен анализлау белгечлеге буенча 1940—41 нче уку елы өчен

аспирантлар ала

Аспирантурага экономик юнәлеш буенча, тәгәлләнгән югары белемле кешеләр алыналар.

Гариза белән бергә, керүченең автобиографиясе, югары уку йортын тәгәлләү турында бирелгән диплом, гаскәри хезмәткә мөнәсәбәте турында документ һәм соңгы хезмәте урыннан характеристика бирелергә тиеш.

Гаризалар шушы ел 1 нче июньнан 15 нче августка кадәр алына.

Белешмәләр институт канцеляриясендә бирелә. Казан Карл Маркс урамы, 43, Казан Финанс-Экономика институты. 537—1

СССР НАРКОМЗДРАВЫНЫҢ

КАЗАН ПСИХИАТРИЯ БОЛЬНИЦАСЫ

(Ершов кыры, 5, телефон 32)

медика санитария учреждениеләренә һәм Казан шәһәре халкына белдерә:

Стационар рәвештә дәвалау өчен авырулар шушы ел 1 нче апрельдән (больницага ашыгыч рәвештә салынырга тиешле авырулардан башка) район психиатрлары тарафыннан бирелгән путевкалар буенча гына алыначак.

Амбулаториядә дәвалау өчен авыруларны кабул итү һәм авырулар янына район психиатрларны чакыртуны язу түбәндәге урыннарда үткәрелә: Бауман һәм Ленин районнарындагы авырулар өчен—1 нче номерлы үзәк поликлиникада (Красный урамда, кабул итү көндез 3 сәгатьтән), Молотов һәм Киров районнарындагы авырулар өчен—2 нче номерлы поликлиникада (Кәмлев урамында, кабул итү көндез 3 сәгатьтән), Сталин районындагы авырулар өчен—Вахитов поликлиникасында (Тукай урамы, кабул итү көндез 4 сәгатьтән). 534—3—1

Казандагы 1 һәм 2 нче номерлы нефтебазалар бер — хуҗалыкка берләште һәм берләштерелгән база —

КҮЧЕРҮ-БУЛУ КАЗАН НЕФТЕБАЗАСЫ

дип яңадан исемләнде.

Дәүләт Банкасы Татарстан Республика конторасында, берләштерелгән базаның расчетлар счеты № 186002. Адрес: Казан, Яңа бистә, Зур Ямашев урамы, 2. 539—1

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ

Татар Дәүләт Академия театры бинасында 28 нче мартта

ФАЙДАСЫЗГА САКЛАНУ

Талоннар белән кертелми.

Коллектив рәвештә килү өчен 29—64 телефоны буенча заявкалар алына.

СССР Наркомлегпромның Укыту Бөтенсоюз Комбинатының

КАЗАН ФИЛИАЛЫ БЕТЕРЕЛӘ

Укыту Комбинатының Казан филиалында укып чыккан гражданнардан үзләренең укырга кергәндә тапшырган документларын шушы ел 1 нче апрельгә кадәр алулары сорала. Казан, Татарстан урамы, 40. 1 нче мәктәп. 536—1

ТАТАРСТАН АССР ОСОАВИАХИМ ҮЗӘК СОВЕТЫНЫҢ

АВТО МӘКТӘБЕ

производстводан аерып укытып III нче класс шоферлар хәзерләү һәм III нче класс шоферлардан II нче класс шоферлар хәзерләү курсларына

УКУЧЫЛАР АЛА

Укучылар учреждениеләрдән һәм предприятиеләрдән бирелгән командировкалар белән алыналар. Казан, Профсоюз урамы 10/14. Телефон 25—43. 389—3—2

КИРӘК:

Фото-Желатин заводы төзелешенә, монтаж һәм эксплоатация буенча эшләү өчен 6—7 нче РАЗРЯД ЭЛЕКТРОМОНТЕРЛАР. Тору урыны бирелә. Казан, Восстание бистәсе, Фото-Желатин заводының кадрлар бүлеге. 474—5—2

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ

Бүген, 26 нчы мартта

БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА

27 һәм 28 нче мартта

ЛЕНИН

29 нчы мартта күңелле комедия ПРЕМЬЕРА

„КУРКЫНЫЧЛЫ" СУД

Талоннар белән кертелми.

Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

Бүген, 26 нчы мартта ял көне. Иртәгә һәм һәр көн

ФРАНЦУЗЧА КӨРӘШ

(һәр көн 3 пар көрәшә) һәм зур программа буенча

ЦИРК УЕНЫ

Уен кич 8 дә башлана.

Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 1 гә һәм кич 5 тән 11 гә кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Художестволы яңа фильм ЗУР ТОРМЫШ. Балалар өчен махсус рәвештә көндезге сеанслар үткәрелә. Билет бәясе 50 тиен
„УНИОН" 12, 2, 4, 6, 8, һәм 10 да.	ПРЕМЬЕРА ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 2, 4, 6, 8, 10 да.	ҺАВА ПОЧТАСЫ
„ЧАТКЫ" 6, 8, 9-30 да.	ҖИР ПЛЕНДА
„ПИОНЕР" 10, 11-30, 1, 2, 3-30, 5-, 6-30, 8-20, 10 да.	ШӘХСИ ЭШ. Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яшьтәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП
„РОТ-ФРОНТ" 6, 8, 10 да.	Гроза
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	КЕЧКЕНӘ АНА

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 1308 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 1142.